ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.21А, д.Малые
Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 21А йорт, Кече
Урыссу авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» ноябрь 2025 ел № 5

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге составына керүче Кече Урыссу торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26, 92 маддәләре нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 21 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Кече Урыссу авылы, Совет урамы, 21а адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссу торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссу торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, Россия Армиясе сафларына хезмәт итәргә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүдән үзара салым кертүгә ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кече Урыссу торак пунктында юлларны кардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Кече Урыссу торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны энергияне саклый торган лампалар сатып алу, урнаштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

- торак пунктта су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (Кече Урыссу торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (җайланмалар һәм

материаллар сатып алу, транспорт хезмәтләре күрсәтү, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Кече Урыссу торак пунктында гидрантларга хезмәт күрсәтү, җиһазлар һәм материаллар сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Кече Урыссу торак пунктында торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (корыган, кипкән агачларны, куакларны кисү (транспорт чыгымнары, эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына Кече Урыссу торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Н.С.Рәфыйков